РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА ЕГОРКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕГОРКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Егоркино ав. КАРАР

«10» ноябрь 2021 ел № 8

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗесе авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Егоркино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Рус Мәнҗесе авылында Октябрьская урамы буенча 17 нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗесе авылында Октябрьская урамы буенча №1-17, 2-18 нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2021 елның 25 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Беренче Яр буе урамы буенча 12 нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗесе авылында Беренче Яр буе урамы 1-27 нче йортттан, 2-24 нче йорттан, Икенче Яр буе урамы буенча 1-35нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Рус Мәнҗесе авылында яшәүчеләрнең исемлеген аеруны сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге Рус Мәнҗесе авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы катнашучыларының тол калган хатыннарыннан, 1нче төркем инвалидлардан кала, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы:

Торак пункт чикләрендә юлларны ремонтлау
« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге Рус Мәнҗесе авылында гражданнар җыенын гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча билгеләү турында» 2011 ел, 5 ноябрь, 4 нче карары үз көчен югалткан дип

7. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Каравыл Тавы авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И.Борисов